Кукмара муниципаль районы Ошторм Юмья урта белем бирү мәктәбе

# Тема. Бәйлек. Бәйлек сүзләр

# (Предлог.Послелог. Послеложные слова. )

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Р.Г. Шакирова

- бир, ал, көл, кит, кайт саубуллаш, гафу ит, аша, эшлә, шатлан, күзалла, җавап бир, укып чык.

- Җәйгә кадәр дүрт ай бар.
- Мин мәктәпкә дустым белән барам. Без дәресләрдән соң төрле түгәрәкләргә йөрибез.

# Тема. Бәйлек. Бәйлек сүзләр

# (Предлог.Послелог. Послеложные слова. )

# Послелоги (бәйлекләр)

- Послелоги по своей грамматической функции соответствуют русским предлогам, но в отличие от них всегда стоят после самостоятельного слова и поэтому называются послелогами. Они управляют определенными падежами.

1. **Баш килешне таләп итүче бәйлекләр:** белән, өчен, кебек, шикелле, төсле, кадәр, чаклы, хәтле, тикле, аркылы, турында.

2. **Юнәлеш килешне таләп итүче бәйлекләр:** таба, күрә, каршы, кадәр, чаклы, хәтле, тикле.

3. **Чыгыш килешне таләп итүче бәйлекләр:** башка, бүтән, бирле, соң, элек.

# Тәрҗемә итәбез: русчадан татарчага, татарчадан русчага.

- С отцом, со мной, за тебя, до леса, как мама , после обеда.
- Шатлык белән, мәктәпкә кадәр, дустым кебек, өйгә таба, әнидән башка.

# Кирәкле сүзләрне куегыз һәм күчереп языгыз.

1. Дусларым … мәктәпкә ашыгам.
2. Бүген дәрестә кыш … инша язабыз.
3. Дәресләрдән … өйгә кайтам.
4. Бакчага … 2 километр барырга кирәк.
5. Мин дә Марат … көчле.

# ТИКШЕРӘБЕЗ

- 1. Дусларым белән мәктәпкә ашыгам.
2. Бүген дәрестә кыш турында инша язабыз.
3. Дәресләрдән соң өйгә кайтам.
4. Бакчага кадәр 2 километр барырга кирәк.
5. Мин дә Марат кебек көчле.

- ... белән бардым,
- ... турында уйлыйм,
- ... таба йөгердем,
- ... өчен сөйлим,
- ... башка бармыйм,
- ... төсле матур,
- ... соң килеп җиттем.

# РЕФЛЕКЦИЯ

- Бәйлекләргә сорау куеп буламы?
- Рус телендә бу сүзләр урнына нәрсәләр кулланыла?
- Сүз тәртибендәге аермалары бармы?

# Өй эше.

**1нче төркем** чыгыш килешне таләп итүче бәйлекләр белән җөмләләр төзергә.

**2нче төркем** юнәлеш килешне таләп итүче бәйлекләр белән җөмләләр төзергә.

**3нче төркем** баш килешне таләп итүче бәйлекләр белән җөмләләр төзергә.